РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

## РЕШЕНИЕ / КАРАР

№ 46

2021 елның 1 сентябре

### Түбән Кама муниципаль район Советының 2018 елның 28 сентябрендәге 65 номерлы карары белән расланган муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында, аларның исемнәрен алыштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль район Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль район Советының 2018 елның 28 сентябрендәге 65 номерлы карары белән расланган муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында, аларның исемнәрен алыштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.6 пунктында «5 ел» сүзләрен «1 ел» сүзләренә, «10 ел» сүзләрен «5 ел» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

А.Р.Метшин